# Зурлар төркеме өчен төзелгән эш программасына аннотация

Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп язылды:

*Федераль дәрәҗәдә:*

- “Закон об образовании вРоссийской Федерации” (Принят 29 декабря 2012года № 273-ФЗ); -“Санитарно-эпидемиологическими требованиями к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных организациях (Постановление от 15 мая 2013 года № 26 “Об утверждении СанПиН 2.4.1.3049-13);
- Приказ Минобразования Российской Федерации “Об утверждении Федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования” от 17.10.2013 № 1155;

*Региональ дәрәҗәдә:*

- “Закон РТ № 44 от 28.07.2004г. “О государственных языках РТ и других языках в РТ”.

Төркемдә белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге түбәндәге программаларга яраклаштырып төзелгән:

- Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү Программасы “От рождения до школы» (под редакцией Н.Е.Веракса, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой Москва «Мозаика-Синтез», 2010;,
- “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы”, Р.К.Шаехова, 2012.
- “Туган телдә сөйләшәбез:методик әсбап/Ф.В.Хәзрәтова,З.Г.Шәрәфетдинова,И.Ж.Хәбибулина.
- Эш программасы түбәндәге норматив документларга таянып төзелгән:

*Җирле дәрәҗәдә*:

15 нче номерлы “Алсу” балалар бакчасы уставы

**Эш программасының төп фикере** - укыту, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау белән бергә баланың шәхесен үстерү.

**Эш программасының күрсәткече:**

*Белем өлкәләрен интеграцияләү нигезендә тулы педагогик процессны төзү;

*Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып төп юнәлешләр – физик, социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти үсеш юнәлешләре буенча төрлеяклап үстерү;

**Программаның эчтәлеге**

Бу программа “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына, Федераль дәүләт таләпләре”нә нигезләнеп, Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан мәктәпкә кадәр”төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү программасына, 15 нче номерлы “Алсу” балалар бакчасының төп белем бирү программасына, шулай ук балалар бакчасының еллык эш планына таянып төзелде. Программаның төп бурычлары-мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру , шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру, шәхсиһәм яшь үзенчәлекләренә яраклаштырып, физик һәм психик сыйфатларны төрле яклап

үстерү, баланы хәзерге җәмгыятьтә яшәргә, мәктәптә укырга әзерләү, мәктәпкәчә яшьтәгебаланың куркынычсыз яшәү рәвешен булдыру.

Бу максатлар бала эшчәнлегенең (уен,аралашу, хезмәт, танып-белү, иҗади, уку) төрле процессларында тормышка ашырыла.

Программаның төп бурычлары :
Милләтенең, теленең, социаль чыгышының нинди булуына карамастан, һәр балада аны яратуларына ышаныч, тормыш өчен җайлы шартлар тудыру;
Шәхси һәм яшь һәм үзенчәлеге буенча балаларның һәрьяклы үсеше өчен уңайлы шартлар тудыру;
Балада социаль-әхлакый, физик, интеллектуаль, эстетик сыйфатларүстерү;
Кеше эшчәнлегенең төп формаларында үзен-үзе ачу һәм иҗат итү сәләтен, ихтыяҗын формалаштыру, дөнья белән берлектә үзен-үзе танып белү, аның белән әңгәмә алып баруга әзерлек;
Баланың гомуми шәхси культурасын, шул исәптән сәламәт яшәү рәвешенең кыйммәтен, белем алу эшчәнлегендә алшартны, инициативасын, мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын, актив тормыш позициясен формалаштыру;
Һәр баланың сәләтен һәм иҗади потенциалын үстерү;
Гуманлык кыйммәтләре һәм идеалы, ирекле кешенең хокуклары нигезендәбаланың башка балалар, өлкәннәр һәм әйләнә-тирә белән үзара йогынтысын оештыру;
Балаларда Ватанга патриотик хис һәм мәхәббәт, рухи-әхлакый һәм социокультура кыйммәтләре нигезендә аның уңышлары өчен горурлану хисе тәрбияләү;
Гаиләнең һәм җәмгыятьнең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә гаиләнең һәм балалар бакчасының тәрбияви-сәламәтлек ресурсларын берләштерү;
Гаилә белән үзара партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру, психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтү, белем һәм тәрбия бирүдә ата-аналарның компетентлылыгын күтәрү;
Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, максат, бурыч, алымнар, мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомумбелем бирү дәрәҗәсендә күчүчәнлекне булдыру.

Эш программасы системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык принципларын истә тотып төзелде.

# Зурлар төркеме өчен төзелгән эш программасына аннотация